**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Иске Маврин авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**09.12.2021** **№46**

**2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1 статья

1. 2022 елга Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 9088,7 мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 9088,7 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0 мең сум күләмендә.

2. 2023 һәм 2024 елларга Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2023 елга 9092,3 мең сум, 2024 елга 9096,2 мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2023 елга 9092,3 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 233,6 мең сум һәм 2024 елга 9096,2 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 458,2 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 2023 елга 0 мең сум, 2024 елга 0 мең сум күләмендә.

3. Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең 2023 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

2. Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең 2024 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең 2025 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга;

3 статья

Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджетында 2022 елга, 2023 - 2024 еллар план чорына Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

1. 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 кушымта нигезендә расларга.

2. 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 кушымта нигезендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджетының халык алдында норматив йөкләмәләрне үтәү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2022 елга 0 мең сум, 2023 елга 0 мең сум, 2024 елга 0 мең сум күләмендә.

5 статья

1. Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджетыннан вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыру буенча төзелгән килешүләр нигезендә Зәй муниципаль районы бюджетына җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен расларга:

- Иске Маврин авыл җирлегендә яшәүчеләрне мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру буенча 2022 елга 4992,3 мең сум, 2023 елга 4936,3 мең сум, 2024 елга 4934,1 мең сум күләмендә;

- авыл торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өлешендә 2022 елга 1426,5 мең сум, 2023 елга 1427,0 мең сум, 2024 елга 1430,0 мең сум күләмендә.

2. 2022-2024 елларда әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына күчерү ай саен, тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6 статья

Зәй муниципаль районы Иске Маврина авыл җирлеге бюджетында хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Зәй муниципаль районы бюджетыннан алына торган субвенцияләрне 2022 елда 103,7 мең сум, 2023 елда 107,3 мең сум, 2024 елда 111,2 мең сум күләмендә исәпкә алырга.

7 статья

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясы нигезендә, Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләрне 2022 елга 57,0 мең сум, 2023 елга 95,4 мең сум, 2024 елга 94,6 мең сум күләмендә расларга.

2. 2022-2024 елларда әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына күчерү ай саен, тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

8 статья

Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2022 елда муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

9 статья

Муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2021 елда түләнергә тиешле товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмый торган күләмдә Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджетының 2022 елның 1 гыйнварына калган акчалары 2022 елда, Зәй муниципаль районының Иске Мврин авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

10 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары, төзелгән килешү нигезендә, Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

11 статья

Әлеге карарны җирле массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru/rus/staromavrinskoe.htm адресы буенча урнаштырырга.

12 статья

Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Иске Маврин авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Р.Г. Нургалеев**